**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Кәкре Елга авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Кәкре Елга авылы № 9-2 «23 » сентябрь 2020 ел

**Кәкре Елга** авыл җирлеге Советының 2018 елның 10 май 93 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге депутатларының, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» карары белән расланган, даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатлар, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының айлык акчалата бүләк күләмен һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Кәкре Елга авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын арттыру һәм үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатлар, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затлары, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Кәкре Елга авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәткә түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында
( 18.06.2018 № 97, от 26.11.2018 № 117 карарлар редакциясендә)

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 06 августындагы 658 нче номерлы «Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында" карары нигезендә

Кәкре Елга авыл җирлеге Советы карар итте:

1. 2020 елның 1 октябреннән, Кәкре Елга авыл җирлеге Советының 2018 елның 10 май. 93 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге депутатларының, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль

хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» карары белән расланган, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының айлык акчалата бүләк күләмен 1,03 тапкыр арттырырга.

2. 2020 елның 1 октябреннән, Кәкре Елга авыл җирлеге Советының 2018 елның 10 май 93 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге депутатларының, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» карары белән билгеләнгән тәртиптә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Кәкре Елга авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең, алар биләгән муниципаль хезмәт вазыйфалары нигезендә, вазыйфаи окладлар күләмен арттырырга.

3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмен исәпләү өчен әлеге карарның 2 пункты нигезендә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладының күләмен 1,03 тапкыр индексацияләргә һәм аны 11 498 сум күләмендә билгеләргә.

4. 2020 елның 1 октябреннән, Кәкре Елга авыл җирлеге Советының 2018 елның 10 май 93 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге депутатларының, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» карары белән расланган, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатлар, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затлары, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Кәкре Елга авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәткә түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.1. 1.5 пунктта «11 163,00» санын «11 498,00» санына алмаштырырга.

4.2. 1 нче кушымтаны, әлеге карарга кушымта нигезендә, яңа редакциядә бәян итәргә.

5. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Кәкре Елга авыл җирлеге бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

6. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис И.М.Мөхәмәтҗанов

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Советы карарына
кушымта
«23» сентябрь 2020 ел

Үз вәкаләтләрен даими рәвештә гамәлгә ашыручы депутатлар, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының айлык акчалата бүләк күләме

| Вазыйфаның атамасы | Авыл җирлекләрендә | |
|---|---|---|
| | 11 группа | 12 группа |
| 1 | 2 | 3 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 17253 | 15759 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары | 12 398 | 11499 |
| Депутатлар | 11498 | 11498 |
| Җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзалары | 11498 | 11498 |